во многих очерках Ш.Ракипова («Возвращение», «Солдатская котомка», «Любовь продолжается» и др.) Другой наиболее часто употребляемый образ в очерках Ш.Ракипова. – неотделимый элемент военной тематики – *образ боевого знамени, образ флага*. Как символ победы над фашизмом, над миром насилия и зла, он веет алыми переливами на куполе Рейхстага («Сохранить навсегда!»), вдохновляет своим величием советских бойцов на борьбу с захватчиком («Есть ивы на берегу Днепра»).

Многозначителен и *образ девичьей косы* в очерках Шамиля Ракипова. Отрезанные девичьи косы, что лежат на дне солдатских котомок, или остались храниться в сундучке, в родном доме девушки-бойца, предстают символом попранной красоты и разбитой светлой мечты. Как видим из очерков Ш.Ракипова, красота может статься источником ненависти и орудием борьбы, однако, в то же время *образ девичьей косы* - это всегда символ надежды, символ веры («Есть ивы на берегу Днепра»).

Ш.Ракипов, как и многие известные татарские писатели, пришел в большую литературу из журналистики. Но, в отличие от других, с начала и до конца творческого пути был верен одной тематике и посвятил свой талант творчество воспеванию доблестного подвига и славного имени героев - наших земляков. Эволюция Ш.Ракипова от журналиста до писателя, рост его художественного мастерства хорошо прослеживается на примере литературных очерков разных лет.

**Литература**


1. Адамович А., Гранин Д. Главы из блокадной книги / А.Адамович, Д.Гранин // «Новый мир». – 1977. - №2.
2. Алексеев В.А. Очерк. Спец. курс для студентов заочн. отд. / В.А. Алексеев. – Л.: Изд-во ЛГУ, 1973. – с.. 84.
3. Әгъзәмов Ф.И. Узәктә - кеше. Очеркларыбыз турында / Ф.И. Әгъзәмов. – Казан: Татар.кит. нәшр.,1981.-. 153.
4. Рәкыйпов Ш.Җ. Геройлар үлмиләр / Ш.Җ.Рәкыйпов.- Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. – 286 б.



**Г.Р. Гайнуллина, А.Ю. Садыкова**
**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**


## Г.САБИТОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ПСИХОЛОГИЗМ БИРЕЛЕШЕ

XX гасырның 60-80 еллар татар прозасы алып килгән яңа юллар балалар прозасы үсешенә дә матур йогынты ясый. Бу дәвердә татар әдәбияты акрынлап иҗтимагый аңлатылышлы психологизмнан гомумән кешенең рухи дөньясын, тарихи һәм иҗтимагый сәбәпләргә бәйләмичә, фәлсәфи кыйммәт дип карауга таба хәрәкәт итә [1:4].

1980-1990 еллар аралыгында татар балалар прозасының психологик канатына Габделхәй Сабитов, Фәнис Яруллиннар салган эчтәлек әдәбиятның яңа дәвергә аяк басуы турында хәбәр итә.

Г.Сабитовның “Урман кызы Таңсылу” (1981) хикәясенә алынган мотивны автор җанр атамасы белән үк тамгалый. Әсәр тукымасына тылсымлы хикәя дип билгеләнгән өлештән үк кереп кителә.

Сюжет сызыгы урман кызын табуга бәйле Булат – Кәли мөнәсәбәтләренә корыла. Кичерешләр сызыгын зирәк карт архетипик моделе һәм аның кабатланышы каймалап ала: “Сәер кеше бу Газизулла абзый. Гомере буе урманда яшәп тә һаман күңеле урманнан бизмәгән” [2:25]. Ата кешенең бурычы – улының күңел тәрәзәләрен ачу дип инанган Газизулла Булатның ышанычын яуларлык гамәлләр генә кыла. Автор-хикәяләүче укучысына курай моңын, Карурман бабай җырын ишеттереп алдан ук психологик эчтәлек дулкынына көйли. Урман кызы Таңсылуның барлыгын белү Булатны сер дөньясына алып керә, ул хәзер аны табу өчен таң вакытында уяу булыр. Шул рәвешле, уяу һәм игътибарлы булу гамьсезлеккә каршы куела.

Булатның кичерешләр чылбырында таң вакыты образына салынган эчтәлек символик укылышлы. Малайның психологик халәтендә гаҗәпләнү, соклану тойгысы балада әлегә ачылып кына килүче күңел күзе турында белдерү урыны: “Гаҗәп.Таң вакытында урман тылсымлы бер төскә керә икән! Агач асларында куе күләгә, тау куышы кебек караңгы. Ә кояш төшкән урыннарда агачлар ачык яшел төстә. Һәр агачта, һәр ботакта меңләгән чык бөртекләре. Аларның һәрберсе, күзләрнең явын алырлык булып, төрле төсләр белән балкый. Үләннәрдәге чыклар да бик кызык: кояш төшкән урында алан өсте көзге кырау төшкән төсле ап-ак, ә күләгә җирдә – куе зәңгәр. Әйтерсең кемдер төн буе зәңгәр буяу сибеп йөргән!” [2:27].

Пейзаж элементы ярдәмендә автор самими бала күңелендә туган һәр яңа хиснең никадәр тулы, бөтенлекле кичерелеше хакында әйтә. Малайның әлеге ачышы алдагы вакыйганы – аланга кергәч урман кызы белән очрашуны әзерли. Таңсылу Булатны кәүсә эчендә каен суы акканын тыңларга, таң энҗесеннән энҗе сәйлән тезәргә өйрәтә. Булат берсүзсез Карурман бабай кызына буйсына, тик ромашка чәчәгенең чык бөртегеннән сәйлән тезү генә җиңел эш түгел икән. Автор кеше күңеленең кылларын энҗе сәйлән белән чагыштырып, күңелне аңлау, рух тирбәнешләрен тыңлау зур хезмәт, тырышлык, сак якын килү сорый дип кисәтә кебек. Ләкин үз күңелең тәрәзәләрен ачу һәркемне матур юлга алып чыга, үз асылын, табигатен аңларга ярдәм итә.Таңсылу образында тупланган Матурлык образы – Булат күңелендә әлеге гүзәллекнең укылышы, табылуы ул: “Бөтенләй якында гына, әлеге каен агачы төбендә Таңсылу басып тора!.. Нинди чибәр кызый! Йөзе алмагач чәчкәсе төсле алсу, чәчләре коңгырт-кара. Дулкын-дулкын булып, бөдрәләнеп иңнәренә төшкән. Яшел чигүле ап-ак күлмәк кигән. Ә күзләре... күзләре нинди! Һавага караса, алар ачык зәңгәр, урманга караса – коңгырт, ә чыклы үләнгә караса, чыклы үлән кебек ялтырый башлыйлар”[2: 29].

Автор-хикәяләүче Булатның кичерешләр сызыгын таң калу ноктасына җиткерә: “Ул иелә-бөгелә үләннәрдән, чәчкә керфекләреннән чык бөртекләре җыеп ала да, аларны неп-нечкә пәрәвез җебенә тезеп, кат-кат итеп муенына тага.Таң энҗеләре шунда ук әллә нинди сихри нурлар белән җемелдәшә башлыйлар. Таңсылу өнсез калган Булатка карап елмая” [2:29].

Күңел кылларының яңа дулкыннары Кәли белән Булатның фотосурәт төшерү һәм ясау вакыйгасында чагылыш таба. Булат төшергән рәсемнәр бөтен кешене таң калырга, болай гади генә тоелган табигать мизгелләренә яңа күзлектән карарга мәҗбүр итәләр. Фотосурәтләрнең “Күңел күзе” газетасына урнаштырылуы берсүзсез символик яңгырашлы. Күңел күзе ачылу – тормыш-чынбарлыктагы гади генә тоелган, инде күнегелгән күренешләргә яңа күзлектән карый алу, һәр мизгелнең матурлыгын тоя башлау, һәр вакыйга-гамәлнең сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булын төшенү ул, ди автор: “Беренче рәсемдә шул кошчык. Ул бер куаклыкның иң түбәнге ботагына кунган да, канатларын җәеп, авызын зур ачып түбәнгә карап тора. Нәрсәгәдер борчылганы, нәрсәдәндер бик нык курыкканы әллә каян күренә.. Ә җирдә кап-кара агулы елан. Гаҗәп! Анысын Булат бөтенләй күрмәгән иде.. Икенче рәсемдә тагын да кызыграк хәл!..Кошчык башка ботакка күчеп утырган. Бераз гына читтәрәк аның оясы. Ояда әле каурый чыкмаган дүрт кош баласы. Куак астыннан бер керпе чыгып килә. Елан, авызыннан ике япьле угын чыгарып, керпегә ташланырга тора... Өченче рәсемдә – кошчык тынычланып балалары янына барып утырган. Ә керпе бик тәмләп кенә елан ите ашап утыра” [2: 38-39]. Дөнья мәдәниятендә  кеше җанын аңлатып килүче кош образы  явызлыкны белдерүче мифологик укылышлы елан образы белән каршылыкта бирелә. Керпе-коткаручының пәйда булуы – матур, камил рух  һәрвакыт яклаучысын таба дигән сүз ул.

Кәли белән Булатның шәхси кичерешләре башкаларга ярдәм итә алу, аларның күңел күзен ачарга мөмкинлек тудыру белән бәйле. Алар үзләре хакында белгертү кирәген тапмыйлар. Димәк, яхшылык эшләү кешегә бәхет китерә, аны сөйләп йөрүнең мәгънәсе юк. Кеше башкаларга ярдәм итә алуы белән бәхетле ул, дип автор Булат белән Кәлинең чын бәхетне аңлауга килүен тасвирлый.

Бәхетле булу юлын бай күңеллелектә күргән малайларга  зирәк карт архетипик моделе буларак аңланган Хозыр Ильясның генотибы Карурман бабай фатиха бирүче: “Аланның аргы ягындагы йөзәр еллык агачлар арасында агачлар кебек үк зур, шундый ук юан бер бабай басып тора.Аның куе яшел сакалы биленә җиткән, озын чәчләре дә, җилкәсенә төшеп, сакалына кушылган. Үзе мәһабәт тә, әллә ничек бик куркыныч та... Юан имән ботакларына охшаган зур кулларын бер югары күтәрә, бер түбән төшерә, уңга-сулга селтәп җибәрә, кискен хәрәкәтләр белән башын чайкый, сакалын селки. Аның хәрәкәтләренә буйсынып, урман җыры тагын да үсә, ныгый, дәһшәтле бер көч белән яңгырый башлый”[2:41-42]. Урман җыры образына малайларның күңел җыры мәгънәсе салына.

Карурман бабай сүзләре архетипның кабатланышы булып хикәяне каймалап алган Газизулла теле белән әйттерелә, автор-хикәяләүченең укучыга әйтергә теләгән фикере буларак кабул ителә: “Юк, балалар, урманда сез куркырлык бернәрсә дә юк. Шатланыгыз гына, сезнең күңел күзләрегез ачылган. Күңел күзе чыклы алан өстеннән күтәрелгән ак томанны да гүзәл урман кызы итеп күрә, карт имәнне дә серле дирижерга, җырчы Карурманга охшата. Менә инде хәзер минем күңел тыныч. Сез Карурман җырын ишеткәнсез. Кабат беркайчан да ул сезнең күңелегездән чыкмас. Саф күңелле кеше булып үсәрсез”[2:42]. Шул рәвешле, автор кичерешләр чылбырын

табигать сурәтенә, портрет, пейзаж элементларына, мифологик образ, мотивларга салып тезә.

Г.Сабитовның “Тармаклы яшен” (1984) хикәясендә әтисенең авыр хәлдә ятуы белән килешә алмаган Әлифә күңелендә барган хисләр тасвирлана. Гаиләдәге төпчегеп үзе үргән тал бишектә тибрәтеп үстергәнгәме, Әлифә әтисен аерып ярата, якын итә. Кече яшьтән үк машинага утырып йөргән кызга авылкешесе ирдәүкә дгән кушамат тагарга да өлгерә. Әтисе Кәримнең үпкә шеше белән аяктан егылуы яшенле яңгыр астында баткан машинаны коткарганнан соң була. Машинада булганга кыз үзен гаепле саный.

Кызның кичерешләр дулкыны ретроспектив вакыт белән хикәяләүче тарафыннан бәян ителә. Г.Сабитовка хас булганча, хис-кичерешләр сызыгы психологик вазифа башкарган пейзаж һәм психологик портрет детальләренә салып көчәйтелә: “Менә алар басу юлы буйлап Шелләурамнары ягына чабалар. Машина моторы гөжләп эшли. Кабина тәрәзәсеннән кергән җиләс җил борынга әллә нинди кыр чәчәкләре исе китерә. Ә юлның як-ягында күз күреме иңли алмаслык иксез-чиксез кырлар! Колач салып йөзәсе иде, чумып-чумып уйныйсы иде шул яшел диңгездә!”[2:70]. “Әти кеше боларның барысын да күрә. Кызының күзләрендә уйнаган чаткылардан, борын канатларының еш-еш тирбәлүеннән, хәтта нәзек кенә бармакларының тынгысыз хәрәкәтеннән искәрә ул аларны” [2:69]. Биредә ис, тавыш, төс образларын хис сызыгына күчерү аша автор бер-беренә иң матур хисләрне бүләк итә алган ата-бала мәхәббәте җылысын да, тормышны мәгънәле итүче туган җирне ярату хисен дә чагылдыруга ирешә алган. Әтисенең терелеп кайтуына һәм сөекле кызын иң ышанычлы юлдаш дип мактавына сөенгән кызның кичереш дәрәҗәсен сурәтләү өчен автор тышкы белдерелешкә – дәшми калу алымына мөрәҗәгать итә: “Аннары, очынып-канатланып, урам буйлап йөгереп китә. Кая барганын, ник шулай ашкынганын үзе дә белми...” [2:75]

Г.Сабитов балаларга атап язылган әлеге хикәяләрендә кешенең рухи дөньясын фәлсәфи кыйммәт дип карауга ирешә. Авторның прозаны үстерүгә керткән бер өлеше дә шул сыйфат белән билгеләнә. “Тармаклы яшен” хикәясендә автор-хикәяләүче давыллары-бозлары гына булмасын дип туган җиренә теләк теләүче кызның күңел кичерешләрен сөйләп бирүне фәлсәфи мотивлаштырып йомгак ясый: “Чын мәгънәсен, олы мәгънәсен әле төшенеп тә җитмәстән, басу-кырларга, буразналарга, туган туфрагына күңеленнән шуны тели иде кыз бала” [2:75].

Г.Сабитов хикәяләре – татар прозасының энҗе сәйләне ул. Әдипнең барлык хикәяләре психологизм бирелеше ягыннан мөһим, кызыклы һәм берсүзсез өйрәнелүгә лаек.

**Әдәбият**

1. Заһидуллина Д. Кереш / Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

2. Сабитов Г. Кайнар туфрак: Хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2001.–160 б.